

Декабрь ае башы истәлекле коннәргә бай. 2024 елнын 3 декабрендә, Россиядә истәлекле дата - Билгесез солдат коне билгеләп vтелә. Темников районы Митрялы авылы китапханәсе заведующие Венера Рәшит кызы Ялышева белән Митрялы клубы заведующие Зәйнәб Шамиль кызы Утешева һәм Н.Авкимановский авыл клубы заведующие Николай Иванович Чапаев бу кон алдыннан башта һәйкәлнен тирә-ягыннан карны чистарттылар, ә бәйрәм конне чәчәкләр куйдылар. “...Бу конне безгә шушы искиткеч доньяны һәм аяз кvкне бvләк иткән батыр солдатларыбызнын ныклы иманын һәм фидакарьлеген искә тошерергә кирәк. Кайбер исемнәре билгеле булмаса да, без бу кешеләргә бәхетебез һәм тормышыбыз очен һәрвакыт рәхмәтле булачакбыз”, - дип язылган иде сайтларында.



Мордовиядәге һәрбер мәктәптә дә Билгесез солдат коненә багышланган чаралар vтте. Тагы Инвалидлар коне дә, Юристлар коне дә 3 декабрьдә иде; мона да багышлап чараларнын торлесен уздырганнар. Мәсәлән, Саранскта Билгесез солдат коне унаеннан, “Хәтер шәме” акциясе узды. Ә тугызынчы декабрьдә Ватан Геройлары коне билгеләп vтелә. Бу конне Саранскнын Жинv мәйданында Боек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасы булды. Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары, Татар Пешлә авылы администрациясе,

клубы, китапханәсе вәкилләре белән бергә, һәйкәлләре янында зур чара vткәргәннәр.
- Һәлак булганнар истәлегенә vткәрелгән бер минут тынлык безнен һәрберебезгә бvген булган тынычлык һәм ирекнен бәясе турында уйланырга момкинлек бирде. Шуны истә тотарга кирәк, безнен һәрберебез илебезне саклаучылар турындагы хәтерне сак-лауга vз олешен кертә ала. Мондый чаралар жәмгыятьне берләштерvгә һәм граждан жаваплылыгын формалаштыруга ярдәм итә, - ди Сабина Руслан кызы Макунина, Татар Пешлә мәктәбенен тәрбия һәм ижтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек буенча директор кинәшчесе.